Шәһәр күләмендә җәмгыять белеме фәненнән татар телендә үткәрелә торган олимпиаданың йомгаклау этабы биремнәре
2024-2025 нче уку елы
8-9 нчы сыйныфлар

Эш вакыты – 90 минут
Гомуми балл – 100

1. Сорауларга җавап бирегез. Әгәр сезнең җавабыгыз түбәндәге гыйбарә белән туры килсә, “<u>әйе”</u>, туры килмәсә, “<u>юк”,</u> дип билгеләгез. Җавабыгызны таблицага языгыз (Дөрес җавап 1 балл. Барлыгы 6 балл).

1.1. Катнаш икътисади система хәзерге дөньяда иң киң таралган икътисади система төре булып санала.
1.2. Россиядә гадел хөкем (правосудие) полиция тарафыннан да гамәлгә ашырыла ала.
1.3. Халыкның сәяси хокукларын сизелерлек дәрәҗәдә чикләү монархия билгеләренең берсе булып тора.
1.4. Эсперанто Латин Америкасы илләренең берсендә киң таралган милли дин үрнәге булып тора.
1.5. Кодекслар актларга караганда күбрәк юридик көчкә ия.
1.6. Россия парламенты (Федераль Җыелыш) ике палатадан тора.

Җавап:

1.1.	1.2.	1.3.	1.4.	1.5.	1.6.

2. Лингвистик конструктор. Тәкъдим ителгән сүзләрдән төшенчәнең билгеләмәсен төзегез һәм язып куегыз, төшенчәне атагыз. Билгеләмәнең дөрес сүз тәртибен китерү – 1 балл. Билгеләмәне атау – 2 балл. Барлыгы 9 балл.

2.1. Хокукый, һәм, төркем, әхлакый, белән бәйләнгән, җаваплылык, нигезләнгән, кан кардәшлегенә, кече, никахка, яки.

_____

_____

2.2. Бер-берсенә, ир белән, җәмгыятькә карата, билгеләүче, хатынның, тулаем, хокукларын, формаль, һәм, бурычларын, күрсәтмәләр.

_____

_____

2.3. Төзелгән, законнар, сайлаулар, югары, юлы белән, хакимият, чыгара торган, органы, вәкаләтле.

_____

_____

3. Сорауларга җавап бирегез. Дөрес җавап астына сызып куегыз. Дөрес җавап өчен 2 балл. Барлыгы 6 балл.

3.1. 2024 елда Россиянең дәүләт бюджеты керемнәре 975 трлн. сум тәшкил итте, ә чыгымнары – 995 трлн. сум. Бу күрсәткечләр ил икътисадының нинди күренешен чагылдыралар?

1) икътисадта дәүләтнең роле күтәрелүне
2) бюджет җитмәүне (дефицит)
3) кулланучылар сораулары (спрос) кимүне
4) базарның тәкъдиме үсүе

3.2. Нинди хокуклар бала хокукларына карый?

1) кайгыртучанлыкка һәм тәрбиягә хокуклы булу
2) тәрбия юлларын сайлап алуга хокук
3) ата-аналарының милкеннән ирекле файдалану хокукы
4) никахлашкан вакытта ата-аналарыннан булышлык алу хокукы

3.3. Дин, фән, мәгариф иҗтимагый тормышның нинди өлкәләрен чыгылдыралар?

1) икътисади 2) сәяси 3) социаль 4) рухи

4. Тәкъдим ителгән сүзләр рәтендә кайсысы артык? Дөрес җавап өчен 1 балл. Барлыгы 2 балл.

4.1. гимн, герб, флаг, скипетр

Җавап: _____

4.2. РФ Югары Суды, РФ Конституцион Суды, Конституцион Җыелыш, РФ Югары Арбитраж Суды

Җавап: _____

5. Түбәндәге ситуацияләрне хокук нормалары күзлегеннән чыгып анализлагыз. Дөрес һәм тулы җавап өчен 3 балл. Барлыгы 9 балл.

5.1. Суд карары буенча урлау өчен иректән мәхрум ителгән 15 яшьлек Газизов, суд карары буенча хокукый сәләтсез (недееспособный) дип танылган 20 яшьлек Умаров һәм техникумда укучы 17 яшьлек Кәримов җирле үзидарә органнары сайлауларында катнашырга кертелмиләр. Бу очракта гражданнарның хокуклары бозылмыймы?

Җавап:_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

5.2. 17 яшьлек Рахимовны менеджер вазифасына кабул иткәндә, предприятиенең кадрлар бүлеге аннан паспорт, хезмәт кенәгәсе, мәктәп аттестаты, гаилә составы турындагы справка һәм мәктәптән характеристика таләп итәләр. Эш бирүченең гамәлләре хаклымы? Эшкә кабул иткәндә нинди документар соралырга тиеш?

Җавап:_____

_____

_____

_____

_____

_____

5.3. 17 ярым яшьлек Наиль балигъ булган Наилә белән өйләнешә. Өйләнешкән вакытта, Наиль аны тәрбия итүче (попичительство) Фәридә Галиевна карамагында була. Сезнеңчә өйләнешкәннән соң Наиль Фәридә Галиевна попечительлегендә калачакмы? Җавабыгызны аңлатыгыз.

Җавап:_____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

6. Икътисади мәсьәләне чишегез. Барлыгы 6 балл.

Дамир А банкына бер елга 10% ставка белән акча сала. Керем буенча процентлар срок ахырында бер тапкыр исәпләнә. Бер елдан соң Дамир банкка керткән акчасын шул ук шартларда озайтты һәм вкладка җыелган процентларны өстәде. Шамил Б банкына бер елга 9% ставка белән акча сала. Керем буенча процентлар срок ахырында бер тапкыр исәпләнә. Бер елдан соң Шамил Б банкындагы кертемен тагын бер елга 12% ставка белән озайтты һәм вкладка җыелган процентларны өстәде.

6.1. Процентларда Дамирның 2 ел эчендә үзенең кереме буенча табышын күрсәтегез (2 балл).

Җавап:_____

_____

_____

_____

6.2. Процентларда Шамилнең 2 ел эчендә үзенең кереме буенча табышын күрсәтегез (2 балл). Җавапны бөтен санга кадәр түгәрәкләгез.

Җавап:_____

_____

_____

6.3. Мәликә квартал саен капитализацияле счетка, еллык 12% белән бер елга ача салырга исәпли. Сезнеңчә аның кереме Дамир һәм Шамил кеременә караганда отышлырак булырмы?

Түбәндәге вариантлардан дөрес җавапны сайлагыз.

1. Мәликәнең кереме Дамирныкына караганда отышлырак, ләкин Шамилнекеннән кимрәк булачак.
2. Мәликәнең кереме Шамилнекенә караганда отышлырак, ләкин Дамирныкыннан кимрәк булачак.
3. Мәликәнең бер ел эчендәге кереме, Дамир белән Шамилнең ике ел эчендәге кеременнән азрак булачак.
4. Мәликә, Дамир белән Шамилнең ике еллык кеременә караганда, бер ел эчендә зуррак керем алачак.

Җавап:_____

_____

7. Түбәндә бирелгән текста хаталы мәгълүмат булган өч җөмлә бар. Шуларны табып билгеләгез. Дөрес җавап өчен 1 балл. Барлыгы 3 балл.

(1) Рәсәй мәгариф системасы үз гражданнарына белем алуның киң мөмкинлекләрен бирә. (2) Гомуми белем бирү һәм һөнәри мәктәпләреннән тыш балаларга һәм олылырга өстәмә белем бирү мәктәпләре дә эшләп килә. (3) Өстәмә белем бирү системасына һөнәри колледжлар һәм техник лицейлар керә. (4) Барлык өстәмә белем бирү системасы түләү принцибына нигезләнгән. (5) Өстәмә белем бирү кысаларында балалар өчен музыкаль, сәнгать һәм спорт мәктәпләре эшләп килә. (6) Олылар өчен өстәмә белем бирү магистратура һәм аспирантура белән күрсәтелгән.

Җавабыгызны җөмлә саннары белән күрсәтегез.

Җавап: _____

8. Бирелгән терминнар нигезендә таблицаны тутырыгыз. Дөрес җавап өчен 1 балл. Барлыгы 11 балл.

РФ Президенты, РФ Дәүләт хакимияте, Федераль Җыелыш, РФ Хөкүмәте, РФ судлары, Федерация Советы, Башкарма хакимият, Дәүләт Думасы, Дәүләт башлыгы, Закон чыгаручы хакимият, суд хакимияте



9. Түбәндә бирелгән текстны укып чыгыгыз, анда кайбер сүзләр төшереп калдырылган. Тәкъдим ителгән исемлектәге сүзләрне буш урыннарга язып чыгарга кирәк. Дөрес җавап өчен 2 балл. Барлыгы 12 балл.

«Гаилә – ул _____(1) һәм (яки) канкардәшлеккә нигезләнгән кече _____(2), аның әгъзалары бергәләп яшәү һәм хуҗалык алып бару, хисле элемтәләр, бер-берсенә мөнәсәбәттә уртак _____(3) белән берләшкән. Шулай ук социаль_____(4) да гаилә дип атала, ягъни кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең ныклы формасы, шул калыпларда тормышка ашырыла, ягъни кешеләрнең көндәлек тормышының төп өлеше, җенси мөнәсәбәтләр, бала тудыру һәм балаларны беренче _____(5), көнкүрешне алып баруның төп өлеше, белем алу һәм медицина хезмәте күрсәтү, аеруча _____(6) һәм өлкән яшьтәгеләргә карата мөнәсәбәттә».

Исемлектәге сүзләр баш килештә, берлек санда бирелгән. Аларның саны текстта төшеп калган сүзләр саныннан күбрәк булуына игътибар итегез.

А) балалар	В) коллектив	Е) мөнәсәбәт	И) хөрмәт
Ә) өйләнешү	Г) бурычлар	Ж) төркем	
Б) социальләшү	Д) институт	З) мәхәббәт	

Түбәндәге таблицада бушлыкларның саннары күрсәтелгән. Һәр сан астына үзегез сайлап алган сүзләргә туры килгән хәрефләрне язып куегыз.

1	2	3	4	5	6

10. Таблицаны тутырыгыз. Дөрес җавап өчен 3 балл. Барлыгы 6 балл.
Законнар иҗат итү процессы берничә төп этаптан тора. Калган ике этапны язып бетерегез.

1. Дәүләт Думасына закон проекты кертү
2. Дәүләт Думасында закон проектын тикшерү
3. Дәүләт Думасында законны кабул итү
4.
5.

11. РФ Дәүләт Думасының мәгълүмати-аналитик бюллетене нигезендә 2024 елның көзге сессиясе аралыгында гражданнардан, предприятияләрнең хезмәт коллективларыннан, профсоюз оешмаларыннан, хезмәт һәм сугыш ветераннары советларыннан һәм башка иҗтимагый оешмалардан 13275 хат һәм телеграмма каралган. Гражданнарның мөрәҗәгатьләренең төп темалары түбәндәге диаграммада күрсәтелгән. Шуңардан чыгып, сорауларга җавап бирегез. Барлыгы 12 балл.



11.1. Дәүләт Думасына җәмгыять тормышының кайсы өлкәсенә караган сораулар күбрәк юлланылган? (1 балл) Әлеге тематикага караган мөрәҗәгатьләр санын языгыз (1 балл).

_____

_____

_____

_____

11.2. Сезнеңчә, бу өлкәдәге закон проектлары белән гражданнарның кайсы категорияләре күбрәк кызыксына? Өч төрле категорияне атагыз (Һәрбер категория өчен 1 балл. Барлыгы 3 балл).

_____

_____

_____

_____

11.3. Сезненчә, гражданнар депутатларның игътибарын бу өлкәгә караган кайсы проблемаларга юнәлдергәннәр? Өч төрле проблеманы атагыз (Барлыгы 3 балл).

_____

_____

_____

_____

11.4. Дәүләт Думасына барлык мөрәҗәгатьләр арасында бу өлкәгә гражданнар тарафыннан шундый игътибар булуы нинди сәбәпләр белән бәйле? (Дөрес фаразлау өчен 2 балл. Барлыгы 4 балл).

_____

_____

_____

_____

12. Советлар Союзы геройларының исемнәрен атагыз һәм алырның кыскача батырлыклары турында языгыз. Исемнәрен дөрес билгеләү өчен 3 балл. Батырлыкларын тасвирлаган өчен 3 балл. Барлыгы 18 балл.

1. -

2. -

3. -

1._____

_____

_____

_____

_____

_____

2._____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

3. _____

_____

_____

_____

_____

_____

_____